**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«07» августа 2024 ел № 8

«2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасын раслау турында» Шилнәбаш авыл җирлеге Башщкарма комитетының 2022 елның 13 маендагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 21 июлендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау» муниципаль программасын раслау турында» Шилнәбаш авыл җирлеге Башщкарма комитетының 2022 елның 13 маендагы 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль программаның максатлары булып җирләрне һәм туфракны пычратуны, ярлыландыруны, деградацияләүне, бозуны, юкка чыгаруны һәм җиргә һәм туфракка башка тискәре йогынтыны булдырмый калудан һәм бетерүдән, шулай ук җирләрдән, шул исәптән җирләрнең үзенчәлекләрен яхшырту, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу өчен, рациональ файдалануны тәэмин тора.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе О.А. Чекушкова